ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

23.12.2024 № 1148

**«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча 2024 елга халык өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм Күпфатирлы йортта хезмәт күрсәткәндә һәм гомуми мөлкәтне идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артыграк өзеклекләр белән башкарылган очракта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципального района Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 01 гыйнварыннан торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемлаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен хезмәт күрсәтүләр төрләре буенча билгеләргә, гамәлгә кертергә (1 нче кушымта).

2. Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемлаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) гомуми җыелышта хезмәт күрсәтүләр төрләре буенча торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү составына керүче күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен

түләү күләме күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча яллаучыларга торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү) түләү күләмен исәпләүне расларга (2 нче кушымта). Наем өчен түләү әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпләнгән дифференциацияләнгән ставкалар буенча айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. метрына исәпләнә

4. Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетларына, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә торак урыннар милекчеләренә хезмәт күрсәтүләр исемлеген билгеләү һәм күпфатирлы йортта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү мәсьәләсе буенча җыелышлар уздырганда методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

5. Күпфатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләр составына, күпфатирлы йортның конструктив һәм техник характеристикаларына бәйле рәвештә исәпләнә һәм үзгәрә дип билгеләргә.

6. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы Р.Ш. Хисамутдиновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2024 елның 23 декабрендә номерлы карарына 1 нче кушымта

**2025 елның 01 гыйнварыннан дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемлаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак урыннарын карап тоту өчен хезмәт күрсәтүләр төрләре буенча түләү күләме**

| № т/б | Түләүнең атамасы | Аның өчен түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Күпфатирлы йорт белән идарә итү | Торак урын гомуми мәйданының 1 кв.м нан айга | 5,58 |
| 2 | Гомуми файдаланудагы урыннарның, шулай ук гомуми мөлкәт составына керә торган җир кишәрлегенең санитар тотылышы, шул исәптән:<br>- йорт янындагы территорияне җыештыру;<br>-дератизация (дезинсекция);<br>-контейнер мәйданчыкларын тоту | Торак урын гомуми мәйданының 1 кв.м нан айга | 4,40<br>0,22<br>0,35 |
| 3 | Биналарның һәм башка гомумйорт мөлкәтенең төзелеш конструкцияләренә, инженерлык системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | Торак урын гомуми мәйданы | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -торак бинаны;<br>-лифтларны;<br>- телевидениене коллектив кабул итү системаларын<br>- (гомумйорт) исәпләү приборлары белән җиһазландырылмаган су белән тәэмин итүнең һәм канализацияне йорт эчендәге системаларын;<br><br>салкын суны (гомумйорт) исәпләү приборлары белә җиһазландырылган су белән тәэмин итүнең һәм канализациянең йорт эчендәге системаларын<br><br>- су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге системаларын канализация системасы белән (ЖБО)<br><br>- үзәк җылытуның йорт эчендәге системаларын;<br><br>- йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләре һәм электр җиһазларын;<br><br>- күпфатирлы йортларда газ җиһазларының йорт эчендәге системаларын;<br><br>-вентиляция каналларын;<br><br>- төтен юлларын | ң 1 кв.м нан айга | 5,01<br>5,14<br>0,62<br><br>3,00<br><br>3,10<br><br>1,5<br><br>1,91<br><br>1,54<br><br>0,39<br><br>0,64<br><br>0,64 |
| 4 | Йорт эчендәге газ җиһазларын техник диагностикалау (түләүне исәпләү диагностикалауны үткәрү срогы башланганчы 12 ай эчендә башкарыла) | Торак урын гомуми мәйданының 1 кв.м нан айга | 0,32 |
| 5 | ЖБО чыгару | Торак урын гомуми мәйданының 1 кв.м нан айга | 13,40 |

Искәрмә. Тарифлар өстәлгән бәчгә салымны исәпкә алып билгеләнде.

ТР Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2024 елның
23 декабрендә номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча яллаучыларга торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләменә исәп-хисап тәртибе турындагы нигезләмәгә туры китереп, наем өчен түләү күләменә исәп-хисап**

Наем өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Пн = Нбаз \times \frac{К1 + К2 + К3}{3} \times Ксп \times S,$$

монда:
Пн – торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме;
Нбаз – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында 1 кв.м. торак урынына наем өчен түләү база күләме– **134,50** сум;
Ксп – түләүнең туры килү коэффициенты:
социаль найм шартнамәләре буенча – 0,071;
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча – 0,071;
S – дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча бирелгән торак урынның гомуми мәйданы (кв.м.).

К1 түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К1 = \frac{Км + Ксв + Кпл}{3},$$

монда:
К1, К2, К3, Км, Ксв, Кпл –таблицада күрсәтелгән коэффициентлар.

Таблица

| **Коэффицие** | **Куллану үзенчәлекләре** | **Коэффициент** |
|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** |
| Торк урынының сыйфатын характерлаучы коэффициентлар (К1) | | |
| $К_м$ | Стеналар материалы:<br>- кирпеч, таш;<br>- блоклы, эре панельле;<br>- катнаш яки агач | <br>1,3;<br>1,1;<br>0,8 |
| Ксв | Йортларны кертү сроклары:<br>- 2011 елдан;<br>- 1991 елдан 2010 елга кадәр;<br>- 1971 елдан 1990 елга кадәр;<br>- 1951 елдан 1970 елга кадәр;<br>- 1950 елга кадәр | <br>1,3;<br>1,2;<br>1,0;<br>0,9;<br>0,8 |
| Кпл | Торак урын планировкасы:<br>- яхшыртылган;<br>- стандарт;<br>- стандарт түгел (шул исәптән коммуналь, кунакханә һәм барак тибында, тулай торак) | <br>1,3;<br>1,1;<br>0,8 |
| Торк урынының төзекләндерелүен характерлаучы коэффициент (К2) | | |
| - | Торак урынның төзекләндерелүе:<br>-төзекләндерелүнең бөтен төрләре: салкын, кайнар су белән тәэмин итү, үзәкләштерел гән су чыгару, җылыту (мич белән җылытудан тыш), электр белән тәэмин<br>-төзекләндерүнең бер төре булмау;<br>- төзекләндерүнең бердән артык төре юк | <br>1,3;<br><br><br><br>1,0;<br>0,8 |
| | Йортның урнашкан урынын характерлаучы коэффициент, (К3) | |
| | Урнашкан урыны:<br>Биектау муниципаль районы торак пункты: | 1,3 |